**«Тамчы-шоу» уены положениесе**

Әлеге уен 6, 7, 8 нче сыйныфларда белем алучы укучылардан торган ике команда арасында уйнала. Бер командада 3 кеше, катнашучыларның берсе капитан. Команданың исеме кирәк була, **сәламләү өлеше хәзер юк!!!!**

Студиягә килгәндә һәркемгә үзе белән алмаш аяк киеме алып килү мәҗбүри. Катнашучылар мәктәп формасыннан киенеп килсеннәр. Катнашучы укучыларда үз исемнәре язылган бейджиклар булса бик яхшы (**татарча язылган булсын!!!),** аның зурлыгы гадәти визит карточкасыныкы кадәр булса җитә.

**I тур. "Батыр берне, белемле меңне егар"**. Әлеге турда укучыларга алып баручы тарафыннан сораулар биреләчәк. Сораулар мәгълүм бер тема буенча.

**Сезнең уен темасы: сүз төркемнәре (морфология)**

Командаларга алып баручы сорауны яңгырата, шуннан соң һәр ике команда катнашучылары әлеге сорауга җавапны кәгазьгә яза (язу өчен җайланмалар белән без аларны уен алдыннан үзебез тәэмин итәчәкбез). Сораулар саны 10 булачак. Сорауны алып баручы укый бара, укучылар кәгазьгә язган җавап вариантын экранга күрсәтеп, аларны әйтә бара, ике команданың да җавабы тыңланачак, әгәр җаваплар дөрес булса, аларның икесенә дә баллар куелачак. Нәтиҗәдә, һәр команда ничә сорауга дөрес җавап бирсә, шулкадәр очко җыя алачак.

1 турда шулай ук экран белән эш, ягъни практик биремнәр дә булачак.

Өйрәнеп килергә:

1.Сүз төркемнәре турында төшенчә,

2. Исем сүз төркеме (билгеләмә, ялгызлык һәм уртаклык исемнәр, исемнәрнең берлек һәм күплек төре, исемнәрнең килеш белән төрләнеше, исемнәрнең тартым белән төрләнеше, тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше, исемнәрнең ясалышы ягыннан төрләре, исем ясагыч кушымчалар, синоним һәм антоним исемнәр);

3. Сыйфат (сыйфат турында төшенчә, сыйфат дәрәҗәләре, сыйфатларның ясалышы ягыннан төрләре, сыйфат ясагыч кушымчалар, синоним һәм антоним сыйфатлар, сыйфатларның җөмләдә кулланылышы);

4. Сан (сан турында төшенчә, сан төркемчәләре, саннарның төзелеше һәм язылышы, саннарның җөмләдә кулланылышы)

5. Алмашлык (алмашлык турында төшенчә, зат алмашлыклары, тартым алмашлыклары, сорау алмашлыклары, күрсәтү алмашлыклары, билгеләү алмашлыклары, билгесезлек алмашлыклары, юклык алмашлыклары, алмашлыкларның төзелеше һәм дөрес язылышы);

6. Фигыль (фигыль сүз төркеменең мәгънәсе, фигыльнең башлангыч формасы һәм барлык-юклык төрләре, фигыльнең зат-сан белән төрләнеше, фигыль төркемчәләре)

**II тур.** Видеотабышмакта укучыларга Казан шәһәрендә урнашкан бер һәйкәл турында сөйләнеләчәк, аның фотосы укучыларга тәкъдим ителә. Шуннан чыгып, командага әлеге һәйкәлне атарга кирәк булачак. Өйрәнү өчен: Кол Гали һәйкәле, Карл Фукс һәйкәле, Гавриил Державин һәйкәле, Казан Кремлен төзүчеләр һәйкәле, Муса Җәлил һәйкәле.

**III тур.** Катнашучыларга бирелгән бер озын сүздән мөмкин кадәр күбрәк уртаклык исемнәр төзергә кирәк була. Иң элек озын сүзне эзләп табарга кирәк. Мәсәлән, ҮТСМӘЗЕЗ – СҮЗТЕЗМӘ (сүз, тез, үт, һ.б.ш.) Сүзне тапкан командага бер балл куела.

**3 турның** икенче өлеше дә булачак. Экранда укучыларга хаталы итеп язылган сүзләр тәкъдим ителә. Мәсәлән, килешү кәгәзе, мәкәлә язу, сәнгат белгече, нихаят, руһи хәзинә, тәбигат почмагы. Укучыларга шулардагы хаталарны табу бурычы куела.

**IV тур**. Бу – капитаннар ярышы. Капитаннарга “Тиз җавап” биреме тәкъдим ителә. Төрле фән буенча гыйбарәләр әйтелә, ул дөрес булса, раслап, әйе дияргә; дөрес булмаса, юк дияргә кирәк була. Җавап бирү өчен капитанга 1 минут вакыт биреләчәк, күпме дөрес җавап биреп өлгерсә, капитан үз командасына шулкадәр очко өсти. Мәсәлән, Чиполлино маҗаралары» – рус халык әкияте (**юк),** Карлыгач – кышлаучы кош (**юк**), Ил сүзе баш килештә (**әйе)**

Үткәрелү көне: 2 октябрь 2016 ел
Адрес: Казан, Шамил Усманов урамы, 9 йорт
Сораулар булса шалтыратыгыз: 8-9871727234 – Сәрия.